УДК 72.01

*С.М. Ромашкова*

# БИЛӘР АВЫЛЫ ТӨБӘК ӘҺӘМИЯТЕНДӘГЕ ТАРИХИ ҖИРЛЕГЕНЕҢ «ҖИРЛЕК РУХЫ»Н АЧЫКЛАУ

Статья посвящена выявлению «духа места» исторического поселения регионального значения села Билярск, расположенного в Алексеевском районе Республики Татарстан. Необходимость в выражении «духа места» обосновывается современной архитектурно-градостроительной теорией и требованиями стандартов по охране культурного наследия. Рассматриваются исторический, градостроительный, научный, идеологический и духовный аспекты, формирующие идентичность села Билярск. Анализируется существующий уровень выраженности «духа места» и предложено использование средств архитектуры и благоустройства для его выявления. Обосновывается целесообразность создания археологического парка как формы музея под открытым небом, способной раскрыть особенности историко-культурной среды. Комплексное выявление «духа места» рассматривается как эффективный инструмент сохранения и популяризации культурного наследия и развития туристического потенциала села Билярск.

**Ключевые слова:** дух места, историческое поселение, Билярск, археологическое наследие, археологический парк, городище Биляр

The article is devoted to the identification of the “spirit of the place” of the historical settlement of regional significance of the village of Bilyarsk, located in the Alekseevsky district of the Republic of Tatarstan. The need to express the “spirit of the place” is justified by modern architectural and urban planning theory and the requirements of standards for the protection of cultural heritage. The historical, urban planning, scientific, ideological and spiritual aspects that form the identity of Bilyarsk are considered. The existing level of expression of the “spirit of the place” is analyzed and the use of architectural and landscaping tools is proposed to identify it. The expediency of creating an archaeological park as a form of an open-air museum capable of revealing the features of the historical and cultural environment is substantiated. The comprehensive identification of the “spirit of the place” is considered as an effective tool for preserving and popularizing the cultural heritage and developing the tourist potential of the village of Bilyarsk.

**Keywords:** spirit of the place, historical settlement, Bilyarsk, archaeological heritage, archaeological park, Bilyar settlement

«Җирлек рухы» термины архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә урын охшашлыгын барлыкка китерүче үзенчәлекләр җыелмасы буларак кулланыла. Архитектура теориясендә һәм практикасында «җирлек рухы» төшенчәсен популярлаштыручыларның берсе Норвегия архитекторы Кристиан Норберг-Шульц булды [2]. 1979 елда ул «Genius Loci: Towards a Phenomenologyof Architecture» дигән китабын нәшер итә, анда архитектура феноменологик күзлек-

тән җентекләп тикшерелә. ГОСТ Р 59124-2020 дә болай диелгән: «Дух места: концентрация культурных и художественных событий, материальные и нематериальные, физические и духовные элементы, которые придают территории ее индивидуальный характер, определяют самобытность места, его структуру, окружение, использование, ассоциации, смысловые и эмоциональные аспекты, в том числе в качестве характеристики историко-градостроительной среды» [1].

«Җирлек рухы»н саклау, торгызу һәм ассызыклау – мәдәни мирас объектларын саклау стандартларына кертелгән таләпләрнең берсе. «Җирлек рухы»н ачыклау шулай ук мәдәни мирасны популярлаштыруда нәтиҗәле корал булырга мөмкин. Урын үзенчәлекләрен һәм охшашлыгын ассызыклап, архитекторлар аның асылы турында дөрес күзаллау формалаштырырга һәм, димәк, җәмгыятьтә аның роле, әһәмияте турында мәгълүматны арттырырга сәләтле. Норберг-Шульц язуынча, «архитектураның төп бурычы – урынның “билгеләнеше”н аңлау». Җирлек үзенчәлекләрен чагылдырган биналар кешедә әйләнә-тирәлек белән эмоциональ бәйләнеш формалаштыра: «Шул рәвешле без җирне саклыйбыз һәм үзебез дә бөтенесен үз эченә алган бөтенлекнең бер өлешенә әвереләбез». Норберг-Шульц фикеренчә, кешенең урын белән бәйләнеше булмау, киресенчә, мохиттән читләшүгә һәм аны җимерүгә китерә [6].

Биләр авылы төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге Татарстан Республикасының Алексеевск районында урнашкан. 2002 елның 25 маенда чыккан 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында» Федераль законда тарихи җирлек хакында болай диелә: тарихи җирлек – «ул федераль әһәмияттәге тарихи җирлекләр исемлегенә яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр исемлегенә кертелгән торак пункт яисә аның бер өлеше, реестрга кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары һәм тарихи җирлекнең саклау предметын тәшкил итүче объектлар аларның эчендә урнаша». Тарихи җирлек территориясе Биләр дәүләт тарих, археология һәм табигать музей-тыюлыгы территориясе белән кисешә. Биләр авылы федераль әһәмияттәге «Биләр шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкалаларының берсе» мәдәни мирас объекты территориясен дә өлешчә били. Биләр авылы тарихи җирлегендә химик А.Е. Арбузовның музей-йорты, 1918 елгы революция корбаннарының туганнар каберлеге, шулай ук б. э. к. XVI гасырдан алып б. э. XV гасырына кадәрге чорга караган кырык археологик мирас объекты урнашкан. Әмма тарихи һәйкәлләр күп булуга карамастан, Биләр авылы тарихи җирлеге чикләрендә «җирлек рухы» комплекслы ачыкланмаган.

Тарих күзлегеннән караганда, тарихи Биләр авылының «җирлек рухы»н түбәндәге аспектлар формалаштыра. Бу территориядәге беренче торак пунктлар бронза гасырына карый һәм б. э. к. XVI гасыр белән билгеләнә. Курганнар да әлеге чор истәлекләренә керә. X гасырдан башлап бу җирләрдә болгарлар яши башлый, ә Идел Болга-

рының башкаласы – Биләр тирәсендә төрле авыллардан агломерация барлыкка килә. XIII гасырда Биләр монголлар явы вакытында җимерелә, әмма болгарлар бу территориядә XV гасырга кадәр яшәүләрен дәвам итәләр. Әлеге чор һәйкәлләре бик күп шәһәрлекләрне, авылларны һәм каберлекләрне колачлый. XVII гасырда яңа торак пунктка – Биләр бастругына нигез салына, ул Кама аръягы саклану (засека) сызыгының бер ныгытмасы булып хезмәт итә һәм киләчәктә Биләр авылына әйләнә. Авылларның төрле чорларга һәм мәдәниятләргә караган катламнары охшашлык һәм «җирлек рухы»н барлыкка китерәләр.

Бүгенге көндә Биләр авылының «җирлек рухы»н формалаштыручы әлеге тарихи аспект «Изге чишмә» табигый ызаны территориясендә урнашкан археология музееn, авыл үзәгендәге Биләр авыл җирлеге тарихына багышланган «Биләр. Чишмә башы» (Биляр. Истоки) тематик паркын оештыруда; б.э. X–XIII гасырлар Биләр шәһәрлеген фрагментар музейлаштыруда чагылыш тапкан. Шулай да, Биләргә килүчеләрдә аның тарихи үзенчәлекләре һәм әһәмияте турында дөрес күзаллау булдыру өчен, «җирлек рухы»н ачыклауда гамәлдәге чаралар гына җитәрлек түгел. Урын тарихын күрсәтә алырлык археологик мирас объектларының күбесендә нинди дә булса тану-таныту билгеләре юк һәм, димәк, алар музейлаштырылмаган. Археология музееның проблемасы шунда ки: ул Биләр авылыннан – 2,6 км, Биләр шәһәрлегенең музейлаштырылган өлешеннән 5,5 км ераклыктагы «Изге чишмә» территориясендә урнашкан очракта, музей экспозициясенә кертелгән һәйкәлләрдән аерымлану күзәтелә. Археологик мирас объектлары белән визуаль бәйләнеше булган музей «җирлек рухы»н иң югары дәрәҗәдә күрсәтә алыр иде. Музей бинасыннан шәһәрлек һәм авылларга панорамалы күренеш ачылса, алар ачык һавада күрсәтелүдән тыш, ябулы экспозиция белән дә бәйләнештә булырлар иде. Бу – мәсьәләне чишәргә ярдәм итәргә мөмкин.

Биләр авылы тарихи җирлегенә шәһәр төзү күзлегеннән карaганда, берничә үзенчәлекне билгеләп үтәргә кирәк. X гасырдан алып XIII гасырга кадәр яшәгән Биләр 620 гектарга якын мәйданны биләгән, һәм Урта гасырларның эре шәһәрләре арасына кергән. Бүгенге көндә Биләрдә берничә таш һәм кирпеч корылма калдыклары, шулай ук оборона ныгытмаларына караган чокырлар һәм валлар системасы сакланган.

Биләр шәһәрлегенең хәзерге музейлаштыру дәрәҗәсе борынгы шәһәрнең масштабын бәяләргә мөмкинлек бирми. Ачык һавада музей төзү, Биләрнең бөтен территориясен колачлый торган маршрутлар булдыру юлы белән, мәһабәт тарихи һәйкәлне визуаль рәвештә күрсәтергә мөмкинлек бирер иде. Шулай ук архитектура һәм төзекләндерү алымнарын да кулланып була. Алар кыйммәтле мәдәни катламга зыян китермичә генә тышкы валларның контурын ассызыклар иде. Мондый алымнарга түбәндәгеләр керә: җиңел конструкцияләр ярдәмендә шәһәр контурын реконструкцияләү; валларны калкулыктан шәһәр-

лекне күзәтү өчен җәяүлеләр сукмагы булып та хезмәт итә алырлык контраст төсләрдән торган өслек белән каплау; Биләр периметры буйлап контраст төсле үсемлекләр утырту, алар шулай ук аның чикләрен билгеләр иде.

Хәзерге Биләр авылы һәм Биләр шәһәрлеге территорияләре өлешчә кисешә. Бу – тагын бер шәһәр төзү белән бәйле үзенчәлек. Аны авыл урамнарында, төзекләндерү чаралары ярдәмендә, Урта гасырлар шәһәренең контурларын билгеләү юлы белән күрсәтеп була. Шул ук алымны Биләр бастругы контурларына басым ясау өчен дә кулланырга мөмкин.

Биләр тарихи җирлеге «җирлек рухы»ның шулай ук фән, аерым алганда, археология һәм тарих өчен кыйммәте зур. Әлеге территориядә кырык археологик һәйкәл тупланган, шуларның унысы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына, ә калган утызы ачыкланган мәдәни мирас объектларына карый. Биләр агломерациясенең археологик мирасы XVIII гасырның икенче яртысыннан башлап өйрәнелә һәм бүгенгәчә тикшеренү объекты буларак актуальлеген югалтмый [3]. Археология музее экспозициясенең бер өлеше Биләрдәге археология һәйкәлләрен өйрәнү тарихына багышланган, «җирлек рухы»н ачыклауда моның да кыйммәте бик зур. Әмма бу күренешне соңгы тикшеренүләргә һәм ачышларга багышланган вакытлы экспозицияләр оештыру, шулай ук фәнни-гамәли һәм белем бирү чараларын тагын да интенсивлаштыру ярдәмендә көчәйтергә мөмкин.

Биләр авылының «җирлек рухы»н оештыручы идеологик аспект шунда ки, татар мәдәни үзенчәлеген барлыкка китерүдә төп рольне тарихи җирлек территориясендәге Идел Буе Болгар дәүләте һәйкәлләре, аерым алганда, «Болгар дәүләте башкалаларының берсе булган Биләр шәһәрлеге» уйнады. «Җирлек рухы»ның әлеге өлешен материаль символ булдыру юлы белән ассызыклап булыр иде. Бу алымнан Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында да файдаланганнар: анда болгарларның ислам динен рәсми рәвештә кабул итүенә багышланган истәлекле билге булып хезмәт итүче павильон төзелгән.

Әлеге тарихи җирлекнең «җирлек рухы»н барлыкка китерүче рухи үзенчәлеге – «Изге чишмә» табигый ызанының тылсымга ия булуында. Биләргә күчеп килүчеләр өчен гасырлар дәвамында аның дини әһәмияте зур булган. Биләр авылы «җирлек рухы»ның бу өлеше аеруча нык чагылыш таба. «Изге чишмә» – әлеге тарихи җирлеккә килүчеләр арасында популярлыгы буенча беренче урында. «Изге чишмә»гә ел саен якынча 110 мең кеше килә, бу Биләрдәге башка туристик урыннарга килүчеләр саныннан шактый югары [4]. Шулай ук «Изге чишмә» территориясе – бик яхшы төзекләндерелгән урын да. 2019 елда гамәлгә ашырылган (авторы – «8 линия» архитектура бюросы) табигый ызан территориясен яңарту проекты «җирлек рухы»н ачыклау юлында бер адым булды. Заманча стилистика өстенлек итүгә карамастан, яңартылган «Изге чишмә» архитектурасында беседка һәм

павильоннарны бизәүдә, үткәннәргә мөрәҗәгать итеп, төрки-болгар мотивлары кулланыла.

Санап үтелгән барлык үзенчәлекләр һәм аларны белдерү алымнары ачык һавадагы музейның археология паркы төрендә чагылыш таба ала, чөнки аңа сыгылмалылык һәм вариативлык хас [5]. Археология паркы Биләрдәге барлык археология һәйкәлләрен бер маршрутлар системасына берләштерә, ачык һавада да, музей павильоннарында да төрле экспозицияләр төзи, тикшеренү масштабларын киңәйтү өчен археологик база бинасы булдыра, мәдәни-массачыл чаралар уздыру мәйданчыгы булып хезмәт итә, үзе урнашкан урынның тарихын күрсәтә һәм популярлаштыра ала.

Шулай итеп, Биләр авылы төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлегенең «җирлек рухы»н ачыклау аның мәдәни мирасын саклап калырга һәм популярлаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Археология паркы рәвешендәге музей структурасы булдыру – мәсьәләнең комплекслы чишелеше булыр иде, нәтиҗәдә Биләрдәге барлык археологик һәйкәлләр тарихи җирлек инфраструктурасына кертеләчәк һәм тамашачыларга да алар белән танышу уңайлырак булачак. Әлеге тәкъдимнәр Биләр авылының туристик потенциалын үстерер дип ышанабыз.

**Әдәбият**

1. ГОСТ Р 59124-2020 Сохранение объектов культурного наследия. Состав и содержание научно-проектной документации проекта зон охраны. Общие требования: дата введения 01.01.2021. М.: Стандартинформ, 2020.

2. *Кияненко К.В.* О феномене, структуре и духе места у К. Норберг-Шульца // Архитектурный вестник. 2008. № 3. С. 98–101.

3. *Руденко К.А.* История археологического изучения Волжской Булгарии (X – начало XIII в.). Казань: Республиканский центр мониторинга качества образования, 2014. 767 с.

4. *Шульгин П.М., Шакиров З.Г., Штеле О.Е., Калуцков В.Н., Кутуев А.А., Матасов В.М., Мурашкина С.И.* Концепция перспективного развития билярского музея-заповедника // Наследие и современность. 2021. № 2.

5. *Nikolić E., Anđelković J., Rogić D.* Archaeological Park as a Product of Emotional Design: Design and Organization of a Park Based on the Exploration of Visitors' Emotions // Arheologijaiprirodnenauke. 2011. №. 6. С. 259–270.

6. *Norberg-Schulz C.* Genius Loci: Towards A Phenomenology of Architecture. New York: Rizzoli, 1980.

***Ромашкова Софья Михайловна,***
*Мәскәү архитектура институты (дәүләт академиясе) магистранты*

***Ромашкова Софья Михайловна,***
*магистрант Московского архитектурного института (государственной академии)*
*sofira52@gmail.com*